**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй , Иске Арыш, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2023 елның 27 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй , Иске Арыш,Керәшен Казысы авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- кышкы чорда Балыклы-Чүкәй авылы җирлегендә юлларны карап торуга
- Балыклы-Чүкәй,Керәшен Казысы авылы,Иске Арыш авылында урам утларын,лампаларны сатып алу,карап тору очен
- Балыклы Чүкәй,Иске Арыш,Керәшен Казысы авылларында су системаларын ремонтлау очен
- пожар сундеру машинасын тоту очен (бензин сатып алу)
- Балыклы-Чүкәй авылы жирлегендэге чуплеклэрне чистарту очен

соравы (мәсьәләсе) буенча 2023 елның 23,24 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 517 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенның 262 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 262 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй, Иске Арыш, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында гражданнар җыеннарын булды дип, гражданнар җыеннары нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй, Иске Арыш,Керәшен Казысы авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган

средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- кышкы чорда Балыклы-Чүкәй авылы җирлегендә юлларны карап торуга
- Балыклы-Чүкәй,Керәшен Казысы авылы,Иске Арыш авылында урам утларын,лампаларны сатып алу,карап тору очен
- Балыклы Чүкәй,Иске Арыш,Керәшен Казысы авылларында су системаларын ремонтлау очен
- пожар сундеру машинасын тоту очен (бензин сатып алу)
- Балыклы-Чүкәй авылы жирлегендэге чуплекләрне чистарту очен

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8нче йорт; Иске Арыш авылы,Үзәк урамы,23 В йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 11Б йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башлыгы: И.С.Мазитов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ БАЛЫКЛЫ-ЧУКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000556
БАЛЫКЛЫ ЧҮКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Р 06-2795/02